# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатура килештерү тәртибе турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 1 декабрендә
кабул ителде

1статья. **Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатура килештерелергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары**

Россия Федерациясе Генераль прокуроры Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен үзе тәкъдим итә торган кандидатураны килештерә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы була (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары).

2 статья. **Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны килештерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тәкъдим ителә торган документлар**

Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны килештерү турындагы мәсьәләне карау өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатура буенча Россия Федерациясе Генераль прокуроры тәкъдиме, шул исәптән Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына тәкъдим ителә торган кандидатураның эшлекле сыйфатларын тасвирлый торган документлар кертелә.

**3 статья. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан килештерү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Президенты Россия Федерациясе Генераль прокуроры тәкъдимен кергән мизгелдән алып 30 көн эчендә карый.

2. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерү турында Россия Федерациясе Генераль прокуроры тәкъдимен караганда Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатны шәхси әңгәмәгә чакырырга хокуклы.

**4 статья. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан килештерү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Генераль прокуроры тәкъдимен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының якындагы утырышында карый.

2. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны, тапшырылган документларны алдан карау һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында алга таба карау өчен материалларны әзерләү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профильле комитеты тарафыннан башкарыла. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профильле комитеты утырышына Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидат чакырылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Россия Федерациясе Генераль прокурорына Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерү турындагы мәсьәләне карау датасы хакында хәбәр итә.

4. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында катнашуы мәҗбүри.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны Россия Федерациясе Генераль прокуроры вәкиле йә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тәкъдим итә.

6. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерү турындагы мәсьәләне карау Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**5 статья. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны килештерү (кире кагу) турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителә торган карарлар**

1. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерү (кире кагу) турында Татарстан Республикасы Президентының карау нәтиҗәсе указ итеп рәсмиләштерелә.

2. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерү (кире кагу) турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының карау нәтиҗәсе карар итеп рәсмиләштерелә.

3. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерү (кире кагу) турында карар кабул иткән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатураны килештерүче икенче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына үз карары турында хәбәр итә.

4. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатура Татарстан Республикасы Президенты белән дә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән дә килештерелгәндә генә Татарстан Республикасы белән килештерелгән дип санала.

5. Татарстан Республикасы Президенты указы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия Федерациясе Генераль прокурорына җибәрелә.

**6 статья. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатура кире кагылган очракта килештерү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатура Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының берсе тарафыннан кире кагылган очракта, әлеге кандидатура Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен килештерелмәгән дип санала.

2. Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатура Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының берсе белән генә килештерелгән очракта, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары соңгы карар рәсмиләштерелгән (кабул ителгән) көннән алып җиде көн эчендә килештерү комиссиясе төзиләр.

3. Килештерү комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының берсе тарафыннан Татарстан Республикасы прокуроры вазыйфасына кандидатураны кире кагу сәбәпләрен биш көн эчендә карый. Комиссия үз эшенең нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына хәбәр итә.

4. Килештерү комиссиясе эше нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына Россия Федерациясе Генераль прокуроры тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураны әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кабат карый. Кабат караганда кандидатура Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының берсе тарафыннан кире кагылган очракта, әлеге кандидатура Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен килештерелмәгән дип санала.

5. Килештерү комиссиясе эше йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына кандидатура белән килешү йә бу кандидатураны кире кагу турында кабул ителгән Татарстан Республикасы Президенты указы һәм Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы карары әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Генераль прокурорына җибәрелә.

7 статья. **Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны килештерү турында Россия Федерациясе Генераль прокурорының кабат тәкъдимен карау тәртибе**

Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны килештерү турында Россия Федерациясе Генераль прокурорының кабат тәкъдиме әлеге Законда каралган тәртиптә уза.

8 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 21 декабре
№ 87-ТРЗ